| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2024 п.г.т. Алексеевское № 362

**Татарстан Республикасы Алексеевск vуниципаль районы милкендәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» законнарга туры китереп

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан алына торган,арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.

2. Алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер мәртәбә яисә өлешләп түләү), шулай ук арендалана торган мөлкәтне алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшмәкәрлек субъектының әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә өлешләп түләү срогын сайлау хокукына ия.

3. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе Э.Н.Павловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **О.Н. Леденцов**